ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_23.11.2020 г._ с. Муслюмово №___576___

**Мөслим муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру турында.**

Мөслим муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучы балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, баланслы тукландыру нормаларын үтәүне тәэмин итү максатларында, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясын үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 213н номерлы боерыгы, Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәгариф учреждениеләрендә укучыларны һәм тәрбияләнүчеләрне тукландыруны оештыру буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында» 2012 елның 11 мартындагы 178 номерлы карары, «2020 елга айлык һәм башка төр түләүләр турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 28 августындагы 724 номерлы карары, «2020 елга айлык һәм башка төр түләүләр турында» 2019 елның 28 августындагы 724 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына теркәлгән кушымтага үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 24 августындагы 728 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмаларында башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 октябрендәге 908 номерлы карары, «2021 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 21 сентябрендәге 851 номерлы карары нигезендә, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

1.1. Мөслим муниципаль районы урта гомуми белем бирү мәктәпләре укучыларын ике тапкыр кайнар ризык белән, башлангыч һәм төп гомуми белем бирү мәктәпләре укучыларын кайнар төшке аш белән тәэмин итүне оештырырга;

1.2. Мөслим муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында башлангыч белем бирү программалары буенча укучыларны 53 сум 41 тиен (илле өч сум 41 тиен) түләүсез кайнар төшке аш белән тәэмин итәргә;

1.3. Мөслим муниципаль районының дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү

программалары буенча укучыларга һәр уку көненә ата-ана түләвеннән һәм 8 сум 00 тиенлек субсидиядән торган туклануны оештырырга.

2. Урта гомуми белем бирү мәктәпләрендәге 1-11 сыйныфта укучыга балансланган иртәнге аш бәясен көненә 17 сум, 5-11 сыйныф укучысы өчен балансланган төшке аш бәясен көненә 30 сум; төп гомуми белем бирү мәктәпләренең 5-9 сыйныф укучысына балансланган төшке аш бәясен көненә 30 сум дип билгеләргә.

3. Белем бирү учреждениесендә туклануны оештыру һәм түләү процессы белән бәйле операцияләрне исәпкә алу өчен автоматлаштырылган AVSU.RU (системасы AVSU.RU) - ЭВМ һәм мәгълүмат базалары өчен үзәк программа дигән исәпкә алу системасын кулланырга.

4. Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 150 ст. нигезендә күпбалалы дип һәм «Дәүләт социаль ярдәме турында» 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә аз керемле дип танылган гаилә балалары өчен 8 сум 00 тиенлек (сигез сум 00 тиен) бушлай иртәнге кайнар туклануны оештырырга.

5. «ТР Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ начальнигы Р. Т. Демидовка:

5.1. Укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүгә бүлеп бирелгән акчалардан максатчан файдалануны тәэмин итәргә;

5.2. Витаминнар һәм микроэлементлар белән баетылган төп туклыклы матдәләрнең эчтәлеге буенча балансланган иртәнге һәм төшке ашларның нормаларын һәм сыйфатын тикшереп торуны тәэмин итәргә;

5.3. Мәктәп яны участоклары продукциясе хисабына мәктәп ашлары ассортиментын баету буенча эшне көчәйтергә;

5.4. Гомуми белем бирү оешмаларына продуктларның өзлексез китерелүен координацияләүне һәм контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

6. Укучыларны кайнар ризык белән тәэмин итүче гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

6.1. Мәктәп ашханәләрен сыйфатлы азык-төлек белән өзлексез тәэмин итәргә;

6.2. Гомуми белем бирү учреждениеләрендә гамәлдәге санитария нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә кайнар туклану оештыруга җитештерү контроле үткәрергә.

7. Мөслим муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы» МКУга (Бубекова Н.А.) гомуми белем бирү оешмаларының барлык укучылары өчен уку вакытында туклануны оештыруга бәйле чыгымнарны финанслауны гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә.

8. Әлеге карар 2021 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

9. Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 31 августындагы 454 номерлы карары 2020 елның 31 декабреннән үз көчен югалта дип таныргa.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **М.Р. Бадретдинова**